**ТатарстанРеспубликасы**
**Югары Ослан муниципаль районы Советы Карар № 36-401, 27.08 2018**
**Югары Ослан муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Кагыйдәнамәгә өстәмәләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында " Федераль законның 77нче маддәсенә үзгәрешләр кертү турында" 19.02.2018 № 17-ФЗ Федераль законы һәм "Конкуренцияне яклау турында" Федераль законның 25.1 маддәсенә, Югары Ослан муниципаль районы Уставына туры китереп,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**Карар кылды:**

1. Югары Ослан муниципаль районының 28.12.2017нче ел, №29-321 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Кагыйдәнамәгә түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәнамәнең 1нче Кушымтасының 4нче маддәсен түбәндәге эчтәлектәге 4.2. пункты белән тулыландырырга:

"4.2. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр турында мәгълумат, аларның нәтиҗәләре турында һәм ачыкланган җитешсезлекләрнең нәтиҗәләрен туктату һәм (яки) бетерү буенча күрелгән чаралар турында мәгълумат Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган бердәм тикшерү реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләренә туры китереп бердәм тикшерү реестрына кертелергә тиеш";

2. Физик затлар тарафыннан җирләрне файдалануга муниципаль җир контроле турында Кагыйдәнамә текстын яңа басмада расларга (Кушымта №2).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Советының икътисад үсеше, экология, табигать байлыклары һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә тапшырырга.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**

Югары Ослан муниципаль районы Советы
№ 36-401, 27нче август, 2018нче ел карарына
Кушымта №1

**Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан җирләрне файдалануга муниципаль җир контроле турында**
**Кагыйдәнамә**

Бу Кагыйдәнамә Россия Федерациясе Җир кодексы, “Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль кануны, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль кануны, “Дәүләт җир контролен тормышка ашыручы башкарма властьнең федераль органнарының муниципаль җир контролен тормышка ашыручы органнар белән үзара бәйләнеше Кагыйдәләрен раслау турында” 26.12.2014нче ел, №1515 Хөкүмәт Карары, Татарстан Республикасы Җир кодексы, “Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру тәртибе турында” 13.10.2015нче ел, №83-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы һәм башка норматив хокук актлары белән туры китереп эшләнгән.

## 1. Гомуми кагыйдәнамәләр.

1.1. Бу Кагыйдәнамә Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы кануынының җир мөнәсәбәтләре объектларына карата таләпләрен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль җир контролен тормышка ашыру тәртибен саклауны контрольдә тотуны билгели һәм оештыруны җайга сала, ә аларны бозган очракта Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы кануны белән җаваплылыкка тарту яки башка җаваплылык каралган.

1.2. Муниципаль җир контроле объекты булып Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектлары тора.

1.3. “Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы (алда- Палата) тормышка ашыра. Муниципаль җир контроле функцияләрен башкару өчен җаваплы вәкаләтле затлар булып Палата хезмәткәрләре тора.

1.4. Муниципаль җир контролен тормышка ашырганда Палата дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештә була.

**2. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан җирләрне файдалануга муниципаль җир контроленең максатлары һәм бурычлары**

2.1. Муниципаль җир контроленең максатлары булып җир турында законнарны бозуны кисәтү, ачыклау һәм туктату тора.

2.2. Муниципаль җир контроленең төп бурычлары булып юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан җир турында канунны саклау тора.

2.3. Муниципаль җир контроле үз эченә ала:

- канун белән билгеләнгән җирләрне куллану буенча җирдән файдаланучыларның, хосусый милекчеләрнең, хуҗаларның, арендаторларның бурычларын үтәүне контрольдә тоту;
- җир кишәрлекләрен рөхсәтсез алуны булдырмау тәртибен саклау буенча контроль;
- җиргә хокукны раслаучы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлардан башка җир кишәрлекләрен куллануны булдырмау тәртибен саклау буенча контроль;
- җир кишәрлеген вакытында үзләштерүне контрольдә тоту;
- җирләрне максатчан куллануны контрольдә тоту;
- җир кишәрлеген арендалау буенча килешү вакыты чыкканнан соң җир кишәрлеген вакытында бушатуны контрольдә тоту;
- җирдәрне куллану һәм саклау буенча җир турында канунның башка таләпләрен үтәү.

**3. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан җирләрне файдалануга муниципаль җир контроленең формалары һәм аларны үткәрү тәртибе**

3.1. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Югары Ослан муниципаль районы территориясендә җирләрне файдалануга муниципаль җир контролен тормышка ашыру буенча эшчәнлек формалары булып юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы канунының таләпләрен үтәү буенча җир мөнәсәбәтләре объектларына карата планлы һәм планлы булмаган тикшерүләр тора, ә аларны бозган очракта Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы кануны белән административ һәм башка җаваплылык каралган. Муниципаль җир контролен тормышка ашырган вакытта тикшерү кәгазьләре (контроль сораулар исемлеге) тикшерү үткәргән вакытта муниципаль җир контроле органының дәүләт хезмәтендәге шәхесләре тарафыннан кулланылмый.

3.2. Планлы һәм планлы булмаган тикшерүләр №294-ФЗ Федераль кануны һәм бу Кагыйдәнамәдә билгеләнгән тәртиптә документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

**4. Планлы һәм планлы булмаган тикшерүләр**

4.1. Планлы һәм планлы булмаган тикшерүләрне оештыру “Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль кануны билгеләгән тәртиптә һәм срокларда Россия Федерациясе Җир кодексы билгеләгән үзенчәлекләрне исәпкә алып тормышка ашырыла.

4.2. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр турында мәгълумат, аларның нәтиҗәләре турында һәм ачыкланган җитешсезлекләрнең нәтиҗәләрен туктату һәм (яки) бетерү буенча күрелгән чаралар турында мәгълумат Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган бердәм тикшерү реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләренә туры китереп бердәм тикшерү реестрына кертелергә тиеш.

**5.Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе**

5.1. Тикшерү нәтиҗәләре “Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль канунда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Җир кодексы билгеләгән үзенчәлекләрне исәпкә алып рәсмиләштерелә. Тикшерү акты һәм башка документлар муниципаль җир контролен тормышка ашыруның административ регламентында раслана.

**6. Тикшерү үткәргән вакытта ачыкланган бозу фактларына карата муниципаль контрольнең дәүләт хезмәтендәге шәхесләре тарафыннан кулланылган чаралары**

6.1. Муниципаль җир контролен тормышка ашыру кысаларында тикшерү үткәрелгән вакытта аның өчен Россия Федерациясе кануны белән административ һәм башка җаваплылык каралган җир турында канун таләпләрен бозу ачыкланган очракта, тикшерү актында ачыкланган кимчелекләр турында мәгълумат күрсәтелә. Муниципаль контроль органының дәүләт хезмәтендәге шәхесләре күрсәтелгән актның күчермәсен җир күзәтү дәүләт органына җибәрәләр.

6.2. Муниципаль җир контролен тормышка ашыру кысаларында тикшерү үткәрелгән вакытта аның өчен Татарстан Республикасы кануны белән административ җаваплылык каралган җир турында канун таләпләрен бозу ачыкланган очракта, ачыкланган кимчелекләр өчен җаваплылыкка тарту күрсәтелгән канунга туры китереп тормышка ашырыла.

**7. Тикшерү үткәргән вакытта муниципаль контроль органнарының дәүләт хезмәтендәге шәхесләренең хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы**

7.1. Муниципаль җир контролен тормышка ашыру буенча йөкләнгән вазыйфаларын башкару өчен үзенең компетенцияләре кысаларында муниципаль җир контролен тормышка ашыручы Палатаның урындагы кешесе хокуклы:

- Россия Федерациясе кануны һәм бу Кагыйдәнамә белән билгеләнгән тәртиптә эш таныклыгын күрсәтеп оешмалар һәм объектларга барып чыга ала,

дәүләт власте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар милкендә, кулланылышында, файдалануында һәм арендада булган җир кишәрлекләрен тикшерергә;

- җир турында канунны үтәүне тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар, канун белән каралган җир кишәрлекләренең хосусый милек ияләрен, хуҗаларын, кулланучыларын, арендаторларын, субарендаторларын һичшиксез таныштыру белән башка документлар төзергә;

- җирләрнең торышы, кулланышы һәм саклау турында мәгълуматлар һәм материалларны, шул исәптән муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен кирәк булган җиргә хокукны раслаучы документларны соратып алырга;

- хокук саклау органнарына муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен киртә булып торган гамәлләрне булдырмый калу яки туктатуда булышлык итүне, шулай ук җирләрне куллануны бозуда гаепле затларны ачыклауны сорарга;

- күзәтү һәм контроль функцияләрен тормышка ашыручы башкама хакимиятнең дәүләт органнарына гаепле затларны җаваплылыкка тарту турында мәсьәләне карау өчен гамәлдәге канунны бозу турында материалларны җибәрергә;

- муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен кирәк булган рәсми сорауларны Федераль салым хезмәте инспекциясенә җибәрергә һәм теләсә нинди мәгълуматны алырга;

- муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен кирәк булган җир кишәрлекләренең торышы һәм аларны куллану турында мәгълуматларны һәм материалларны, шул исәптән җиргә хокукны раслаучы документларны бушлай алырга;

7.2. Муниципаль контроль органнарының хезмәттәге затларының тикшерү үткәргән вакытта бурычлары һәм җаваплылыклары “Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль кануны һәм башка норматив актлар белән билгеләнә.

**8. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль җир контролен тормышка ашырганда хокуклары һәм бурычлары һәм аларның хокукларын саклау**

8.1. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары “Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль кануны белән билгеләнгән барлык хокуклар һәм бурычларга ия булалар.

**9. Мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны оештыру һәм үткәрү**

9.1. Палата мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны “Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең

хокукларын яклау турында” 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль кануны белән туры китереп оештыра һәм үткәрә.

**10. Контроль буенча чараларны юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештән башка оештыру һәм үткәрү**

10.1. Контроль буенча чараларны юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештән башка оештыру һәм үткәрү Палатаның хезмәттәге затлары (алда- муниципаль контроль органы) тарафыннан “Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль кануны, күрсәтелгән өлкәдә башка кануннар һәм норматив актлар белән туры китереп үткәрелә.

10.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы муниципаль контроль органнары тарафыннан контроль буенча чараларны юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештән башка оештыруга йөкләмә (алда- йөкләмә) Палата рәисе тарафыннан раслана.

10.3. Йөкләмә бу Кагыйдәнамәгә №1 Кушымта формасы буенча рәсмиләштерелә.

10.4. Йөкләмәдә күрсәтелә:

10.4.1. Чараны үткәрүнең максаты, чараны үткәрү вакыты яки чараны үткәрүне башлау һәм тәмамлау чоры, чараны үткәрү тапшырылган муниципаль контроль органының хезмәттәге заты.

10.4.2. Аңа карата чара үткәреләчәк объект турында мәгълумат: объектның төре, урнашкан урыны турында, шул исәптән аның адресы һәм кадастр (реестр) номеры (булса), объектның биләүче хокукы (булса) турында мәгълуматлар.

10.5. Чара башланыр алдыннан йөкләмә муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан чараны тормышка ашыру йөкләнгән хезмәткәргә тапшырыла.

10.6. Йөкләмәне тапшыру юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештән башка бу Кагыйдәнамәнең №2 Кушымтасы буенча расланган формадагы контроль буенча чаралар журналында (алда- чаралар журналы) имзаланып тормышка ашырыла.

10.7. Чараны үткәрү тәмамлангач чараны үткәргән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Кагыйдәнамә белән туры китереп, чара үткәрү нәтиҗәләрен чагылдырган документлар йөкләмәләр белән бергә чараны тормышка ашырган хезмәткәр тарафыннан Палата рәисенә кире кайтарыла, шул турыда чаралар журналында тиешле билге ясала.

10.8. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештән башка оештырылган контроль буенча чараларның нәтиҗәләре, шул исәптән планлы (рейдлы) тикшерүләр, карап чыгулар, тикшерүләр, үлчәүләр, күзәтүләр муниципаль

җир контроле органы хезмәтендәге шәхес тарафыннан бу Кагыйдәнамәнең №3 Кушымтасы буенча расланган формада чараны үткәрү турындагы акт итеп рәсмиләштерелә.

10.9. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештән башка оештырылган контроль буенча чараларны үткәрү турындагы актта (алда-акт) аны үткәрү тәртибе чагылыш таба һәм үткәрелгән чараның нәтиҗәләре теркәлә. Акт муниципаль җир контроле органы хезмәтендәге шәхес тарафыннан бер нөсхәдә чараны үткәрү тәмамлангач чараны үткәргән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә.

10.10. Актта булырга тиеш: үткәрелгән чара төренә күрсәтмә, чара аның нигезендә эшләнгән бирем турында мәгълуматлар, аның кысаларында чара узган муниципаль контроль төренең исеме, чара үткәрүнең датасы яки үткәрү чоры, аның башлану һәм тәмамлану вакыты, чарада катнашучылар турында мәгълумат, хезмәттәге затның, чарада катнашучыларның гамәлләрен кыскача тасвирлауы, аны үткәргән вакытта алынган мәгълуматлар турында информация, шул исәптән тикшерүләр, карап чыгулар, үлчәүләр, күзәтүләр нәтиҗәләре, алар тарафыннан техник үлчәүләр үткәрелгән техник чаралар турында мәгълуматлар, шулай ук чараларның нәтиҗәләрен (үткәрү барышын) теркәү, актка кушымталар турында мәгълуматлар, шулай ук чарада катнашучыларның аңлатмалары, өстәмәләре һәм күрсәтмәләре.

10.11. Чарада катнашучыларның вәкаләтләре "Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль кануны, муниципаль җир контролен тормышка ашыру өлкәсендәге эшчәнлекне тәртипкә салучы башка кануннар һәм норматив актлар белән билгеләнә.

10.12. Чараны үткәргән вакытта техник үлчәү чараларын һәм фиксация кулланган вакытта алынган схемалар, таблицалар, шул исәптән чараны үткәрү вакытында алынган мәгълумат булган фототаблицалар һәм электрон рәвештә мәгълумат актка кушымта булып тора. Кәгазьдә бирелгән актка кушымталар чарада катнашучы тарафыннан имзалана, электрон рәвештә бирелгән мәгълумат чарада катнашучыларның имзалары белән беркетелеп конвертка салып ябыштырып куела.

10.13. Контроль буенча чараларны үткәргән вакытта мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокук актлары белән билгеләнгән таләпләрне бозу ачыкланган очракта муниципаль контроль органы хезмәтендәге шәхес үзенең вәкаләтләре кысаларында канун белән туры китереп биш эш көненнән дә соңга калмыйча ачылган бозылуларны бетерүгә юнәлтелгән чаралар күрә.

Чара үткәрелгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча муниципаль контроль органы хезмәтендәге шәхес муниципаль контроль җитәкчесенә кирәк вакытта юридик затны һәм шәхси эшмәкәрне "Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 26нчы декабрь, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль канунның 10нчы маддәсенең 2нче өлешенең 2нче пунктында күрсәтелгән нигездә планнан тыш тикшерү

билгеләү турында карар кабул итү өчен ачылган кимчелекләр турында мәгълумат белән язмача мотивлы тәкъдим җибәрә.

10.14. Чара үтәлгәннән соң йөкләмәләр, актлар һәм аларга материаллар тиешле хокук актлары билгеләгән тәртиптә, эшләрнең номенклатурасы белән туры китереп Палатада саклanырга тиеш.

10.15. Актларны һәм аларга материалларны административ хокук бозулар турында эшләрне, суд эшләрен караган вакытта куллану өчен, шулай ук канун белән билгеләнгән башка очракларда чаралар журналында теркәлә һәм муниципаль контроль органы хезмәтендәге шәхеснең имзасы белән беркетелә. Өстәвенә номенклатура делосында тиешле рәвештә күрсәтелгән документларның расланган күчерелмәләре, документлар тапшырылган рәсми сорау күчерелмәләре, шулай ук тапшырылган актларның исемлеге булган бергә теркәп җибәрелә торган документ тегелә.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**

Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр,
дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә
органнары тарафыннан җирләрне
файдалануга муниципаль җир контроле турында
Кагыйдәнамәгә №1 Кушымта

№ _____ йөкләмә

______________________________________________________________

үткәрүгә
(юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнештән башка контроль буенча чараның исеме)

Югары Ослан авылы «____» __________ 20 _____ел.

______________________________________________________________

(йөкләмәне биргән дәүләт хезмәтендәге кешенең вазифасы исеме)

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәтендәге кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

“Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26.12, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль канунның 8.3 маддәсенә туры китереп

______________________________________________________________максатларда

(чараны үткәрү максатын күрсәтергә)
муниципаль контроль органы хезмәтендәге шәхесенә тапшырдым______________________

______________________________________________________________

(контроль орган хезмәтендәге шәхеснең вазифасы исеме, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

______________________________________________________________

юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнештән башка контроль буенча чараны тормышка ашырырга, ягъни :____________________________________

______________________________________________________________

(юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнештән башка контроль буенча чараның исеме)
дата, яки чараны үткәрү вакыты __________________________________________

______________________________________________ тормышка ашыру кысаларында
(муниципаль контроль төре )

______________________________________________________________

______________________________________________________________ объектка кагылышлы
( объект төре)

______________________________________________________________

______________________________________________________________урнашкан
(адресы һәм(яки) кадастр (реестр) номеры (булса))

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(объектның биләүче хокукында (булса) булуы)

______________________________________________________________

______________________________________________________________булган

Раслыйм: _____________________ М.У.
(имза)

Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан җирләрне файдалануга муниципаль җир контроле турында Каныйдәнамәгә

Кушымта №2

Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнештән башка контроль буенча чараларның журналы

_______________________________________________________________________

( муниципаль контроль органының исеме)

| N | Чараны үткәрү турында йөкләмәнең датасы һәм номеры | Чараны тормышка ашыручы дәүләт хезмәтендәге кеше турында мәгълумат, тапшыру турында билге(имза) | Чараны үткәрү датасы (вакыты) | Объектның урнашкан урыны (адресы,теркәлү турында (булса) мәгълумат) | Объектның хуҗасы (фактик кулланучы), хокук билгеләүче документлар (булса) | Чараның нәтиҗәләре турында мәгълумат, акт номеры, йөкләмәне биргән шәхескә материалны тапшыру турында билге | Чараның нәтиҗәләрен саклау (тапшыру) турында мәгълумат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә

органнары тарафыннан җирләрне файдалануга муниципаль җир контроле турында Кагыйдәнамәгә
№3 Кушымта

Акт № _____

_________________________________________________________________үткәрү турында
(муниципаль контроль органы тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнештән башка контроль буенча чараның исеме)

Югары Ослан авылы «____» __________ 20 _____ел

Башланды: _____ с. ____мин.
Тәмамланды: _____ с. ____мин.

___________________________________________________________________________________

(муниципаль контрольне тормышка ашыручы дәүләт хезмәтендәге кешенең вазифасы, органы исеме)

___________________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәтендәге кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

"Дәүләт контролен (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольне тормышка ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 26.12, 2008нче ел, №294-ФЗ Федераль канунның 8.3 маддәсенә туры китереп,

«_____» _________________ 20____ ел., № ___________, бирелгән
___________________________________________________________________________________

(йөкләмәне биргән дәүләт хезмәтендәге кешенең вазифасы исеме)
_______________________________________________________________________________

(чарада катнашучылар турында мәгълумат: фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы һәм башка кирәкле мәгълумат)

___________________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________катна
шында

юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнештән башка контроль буенча чараны тормышка ашырды, ягъни

______________________________________________________________________________

(муниципаль контроль органы тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнештән башка контроль буенча чараның исеме)

_______________________________________________________________

(муниципаль контроль төре)

тормышка ашыру кысаларында

Чара барышында түбәндәгеләр ачыкланды:

______________________________________________________________________________

(чара үткәрү барышын, техник үлчәүләр куллану, шулай ук чара үткәргән вакытта алынган мәгълуматларны теркәүне тасвирлау)

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

Техник үлчәүләр һәм теркәү куллану турында мәгълумат: ____________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

Чарада катнашучылардан килгән гаризалар һәм өстәмәләр турында мәгълумат :

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________ Чарада катнашучылар акт белән ____________________________ юлы белән танышты

(танышу чарасын күрсәтергә )

Катнашучыларның имзалары:

____________________________ (____________________)

____________________________ (____________________)

____________________________ (____________________)

Чараны тормышка ашырган дәүләт хезмәтендәге шәхеснең имзасы _____________________

Югары Ослан муниципаль районы Советы
27нче август 2018нче ел
№ 36-401 карарына
Кушымта №2

**Физик затлар тарафыннан җирләрне куллануны муниципаль контрольдә тоту турында**

**Кагыйдәнамә**

Бу Кагыйдәнамә Россия Федерациясе Җир кодексы,“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль кануны, “Татарстан Республикасы Җир кодексы, “Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру тәртибе турында” 13.10.2015нче ел, №83-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы һәм башка норматив хокук актлары белән туры китереп эшләнгән.

**1. Гомуми кагыйдәнамәләр.**

1.1. Бу Кагыйдәнамә Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы кануны җир мөнәсәбәтләре объектларына карата таләпләрен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль җир контролен тормышка ашыру тәртибен саклауны контрольдә тотуны билгели һәм оештыруны җайга сала, ә аларны бозган очракта Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы кануны белән җаваплылыкка тарту яки башка җаваплылык каралган.

1.2. Муниципаль җир контроле объекты булып Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектлары тора.

1.3. “Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы (алда- Палата) тормышка ашыра. Муниципаль җир контроле функцияләрен башкару өчен җаваплы вәкаләтле затлар булып Палата хезмәткәрләре тора.

1.4. Муниципаль җир контролен тормышка ашырганда Палата дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештә була.

**2. Физик затлар тарафыннан җирләрне куллануны муниципаль контрольдә тотуның максатлары һәм бурычлары**

2.1. Муниципаль җир контроленең максатлары булып җир турында законнарны бозуны кисәтү, ачыклау һәм туктату тора.

2.2. Муниципаль җир контроленең төп бурычлары булып җир турында канунны саклау тора.

2.3. Муниципаль җир контроле үз эченә ала:

- канун белән билгеләнгән җирләрне куллану буенча җирдән файдаланучыларның, хосусый милекчеләрнең, хуҗаларның, арендаторларның бурычларын үтәүне контрольдә тоту;

- җир кишәрлекләрен рөхсәтсез алуны булдырмау тәртибен саклау буенча контроль;

- җиргә хокукны раслаучы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлардан башка җир кишәрлекләрен куллануны булдырмау тәртибен саклау буенча контроль;

- җир кишәрлеген вакытында үзләштерүне контрольдә тоту;

- җирләрне максатчан куллануны контрольдә тоту;

- җир кишәрлеген арендалау буенча килешү вакыты чыкканнан соң җир кишәрлеген вакытында бушатуны контрольдә тоту;

- җирдәрне куллану һәм саклау буенча җир турында канунның башка таләпләрен үтәү.

**3. Муниципаль җир контроленең формалары һәм аларны үтәү тәртибе**

3.1. Җирләрне файдалануга муниципаль җир контролен тормышка ашыру буенча эшчәнлек формалары булып гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы канунын үтәү буенча җир мөнәсәбәтләре объектларына карата планлы һәм планлы булмаган тикшерүләр тора, ә аларны бозган очракта Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы кануны белән административ һәм башка җаваплылык каралган.

3.2. Планлы һәм планлы булмаган тикшерүләр Россия Федерациясе Җир кодексы, “Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру тәртибе турында” 13.10.2015нче ел, №83-ЗРТ Татарстан Республикасы Законына туры китереп үткәрелә.

**4. Муниципаль җир контролен тормышка ашыручы белгечләрнең хокуклары һәм бурычлары**

Муниципаль җир контролен тормышка ашыру буенча йөкләнгән вазыйфаларын башкару өчен үзенең компетенцияләре кысаларында муниципаль җир контролен тормышка ашыручы Палатаның урындагы кешесе хокуклы:

- Россия Федерациясе кануны һәм бу Кагыйдәнамә белән билгеләнгән тәртиптә эш таныклыгын күрсәтеп оешмалар һәм объектларга барып чыга ала, дәүләт власте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар милкендә, кулланылышында, файдалануында һәм арендада булган җир кишәрлекләрен тикшерергә;

- җир турында канунны үтәүне тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар, канун белән каралган җир кишәрлекләренең хосусый милек ияләрен, хуҗаларын, кулланучыларын, арендаторларын, субарендаторларын һичшиксез таныштыру белән башка документлар төзергә;

- җирләрнең торышы, кулланышы һәм саклау турында мәгълуматлар һәм материалларны, шул исәптән муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен кирәк булган җиргә хокукны раслаучы документларны соратып алырга;

- хокук саклау органнарына муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен киртә булып торган гамәлләрне булдырмый калу яки туктатуда

булышлык итүне, шулай ук җирләрне кулլануны бозуда гаепле затларны ачыклауны сорарга;
- күзәтү һәм контроль функцияләрен тормышка ашыручы башкама хакимиятнең дәүләт органнарына гаепле затларны җаваплылыкка тарту турында мәсьәләне карау өчен гамәлдәге канунны бозу турында материалларны җибәрергә;
- муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен кирәк булган рәсми сорауларны Федераль салым хезмәте инспекциясенә җибәрергә һәм теләсә нинди мәгълуматны алырга;
- муниципаль җир контролен тормышка ашыру өчен кирәк булган җир кишәрлекләренең торышы һәм аларны куллану турында мәгълуматларны һәм материалларны, шул исәптән җиргә хокукны раслаучы документларны бушлай алырга;
Муниципаль җир контролен тормышка ашыручы Палатаның дәүләт хезмәтендәге кешесе контроль буенча чаралар үткәргән вакытта бурычлы:
- гамәлдәге канунны үтәргә һәм дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнарның конституцион хокукларын бозмаска;
- муниципаль җир контролен тормышка ашыру буенча чараларны тормышка ашырганда гражданнарның хокукларын саклау буенча канун таләпләрен үтәргә;
- контроль буенча чараларны тикшерү үткәрү турында күрсәтмә нигезендә һәм катгый рәвештә аның белән туры китереп бу Кагыйдәнамә белән билгеләнгән тәртиптә үткәрергә;
- Җир турында канун өлкәсендә хокук бозуларны булдырмый калу, ачыклау һәм туктату;
- ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча үзенең вәкаләтләре кысаларында тиешле чаралар күрү;
- Җир турында канун өлкәсендә хокук бозулар китереп чыгаруга булышлык иткән шартларны юкка чыгару буенча профилактик эш үткәрергә;
- Җир турында канунны бозу турында килгән хәбәрләрне һәм гаризаларны оператив рәвештә карап чыгырга, аларны бетерү буенча үз вакытында чаралар күрергә;
- гражданинга контроль буенча чара үткәргәндә катнашырга комачаулык итмәскә, тикшерүгә кагылышлы булган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;
- гражданинга, яки аның вәкиленә контроль буенча чара үткәргәндә катнашкан вакытта, тикшерүгә кагылышлы булган мәсьәләләр буенча тиешле мәгълуматны бирергә;
- гражданинны, яки аның вәкилләрен контроль буенча чара үткәрү нәтиҗәләре белән таныштырырга.

**5. Җир кишәрлекләренең хосусый милек ияләренең, җирдән кулланучыларның, җир хуҗаларының һәм арендаторларның**

**муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәргән вакытта хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы**

5.1. Гражданнар гражданнарга карата муниципаль контрольне тормышка ашыру кысаларында тикшерү үткәргәндә “Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру тәртибе турында” 13.10.2015нче ел, №83-ЗРТ Татарстан Республикасы Законында каралган барлык хокукларга ия.

**6. Муниципаль җир контролен тормышка ашыручы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең җаваплылыгы**

6.1. Муниципаль җир контролен тормышка ашыручы Палатаның дәүләт хезмәтендәге шәхесләре гамәлдәге канунга туры китереп аерым җаваплы булалар:

- үткәрелгән тикшерүләр буенча әзерләнгән һәм (яки) тапшырылган материалларның гаделлеге, дөреслеге һәм сыйфаты өчен;
- хезмәттәге вазифаларны башкару белән бәйле булган законсыз гамәлләр башкарган өчен;
- хезмәттәге вазифаларны башкару белән бәйле булган вәкаләтләрне арттыру өчен.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**